СОВЕТ
НОВОБУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Вокзальная, дом 31,
П.ж.-д.ст.Бурундуки, Дрожжановский район 422490

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА БОРЫНДЫК
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Вокзал урамы, 31 нче йорт,
Борындык тимер юл ст. поселогы,
Чүпрәле районы
422490

Тел.: (84375) 3-17-45, 3-17-03, факс: (84375) 3-17-45, e-mail: Nbur.Drz@tatar.ru,
www. Nbur -drogganoe.tatarstan.ru

# КАРАР

2021 нче елның 29 октябрь № 14/1

## Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Конституция судының 19.04.20021 ел, № 14-П карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге Советы Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге Советының 2017 елның 13 сентябрендәге 31/1 номерлы карары (2018 елның 22 мартындагы 41/1 номерлы редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренең 135.13 пунктына " тиешле тәртиптә оешкан һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләре милекчеләреннән тыш һәм әгәр бу Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса;" сүзләрен өстәп үзгәреш кертергә.
2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Яңа Борындык авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яңа Борындык авыл җирлеге башлыгына йөкләргә .

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Борындык авыл җирлеге башлыгы: В.Г. Ранцев